ГЛАВА
СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ

с.Степная Шентала

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.10.2020 № 8

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлегенең Кече Кызылъяр авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә

карар бирәм:

1. 2020 елның 11 ноябренә 10 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлегенең Кече Кызылъяр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Кыр Шонталысы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- техниканы карап тоту: трактор, янгын сүндерү машинасы, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы);
- торак пунктта урамнарны яктырту (фонарьлар сатып алу һәм алыштыру);
- контейнерлар өчен мәйданчыклар төзү, контейнерлар сатып алу.

- балалар мәйданчыгын төзекләндерү (сатып алу, мәйданчык элементларын урнаштыру һәм коймалар төзү);

ӘЙЕ ЮК»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан авыл клубы бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Кече Кызылъяр ав., Яшьләр ур., 7 й.

5. Әлеге карарны Кыр Шонталысы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Кыр Шонталысы ав., Вахитов ур., 34 й.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Кыр Шонталысы авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Я.Хәмәдиев**